**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлеге Советы**

Татар Шуган авылы № 146 «03» сентября 2019 ел

Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлеге Советының 14.04.2010 ел № 118 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлегенен бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (12.11.2010 ел №6, 29.10.2011 ел №31, 30.10.2013 ел №73, 08.08.2014 ел №110, 29.10.2015 ел №11, 27.06.2017 ел №57, 13.11.2017ел №72 карарлар редакциясендэ)

25.12.2018 ел №494-ФЗ «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү турында» Федераль закон нигезендә һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлегендә бюджет процессы Нигезләмәләрен Россия Федерациясенең гамәлдәге бюджет законнарына туры китерү максатларында

Татар Шуган авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлеге Советының 14.04.2010 ел № 118 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Татар Шуган авыл җирлегенен бюджет процессы турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында (12.11.2010 ел №6, 29.10.2011 ел №31, 30.10.2013 ел №73, 08.08.2014 ел №110, 29.10.2015 ел №11, 27.06.2017 ел №57, 13.11.2017ел №72 карарлар редакциясендэ) түбәендәге үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә:

1.1. түбәндәге эчтәлекле 18.1 статья өстәргә:

«18.1. Салым чыгымнары исемлеге һәм бәяләү

1. Җирлекнең салым чыгымнары исемлеге муниципаль программалар һәм аларның структур элементлары, шулай ук муниципаль программаларга керми торган эшчәнлек юнәлешләре буенча җирлек Башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә формалаша.

2 Авыл җирлегенең салым чыгымнарын бәяләү ел саен, Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән гомуми таләпләрне үтәп, җирлек башкарма комитеты билгеләгән тәртиптә башкарыла.

3. Әлеге бәяләү нәтиҗәләре җирлекнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләрен формалаштырганда, шулай ук муниципаль программаларны тормышка ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләгәндә исәпкә алына.»;

1.2. 24 статьяның 3-5 пунктларын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3. Җирлек бюджеты турында карар проекты буенча килешмәгән сораулар килеп туган очракта, җирлек Советы Рәисе карары белән килештерү комиссиясе төзелергә мөмкин, аңа җирлек башкарма комитеты һәм җирлек советы вәкилләренең тигез саны керә.

4. Җирлек бюджеты турындагы карар проекты барлык кирәкле документлар һәм материаллар белән җирлек Советына, эшләп бетерү өчен, өч эш көне эчендә тапшырылырга тиеш.

5. Җирлек Советы авыл җирлеге бюджеты турында карар проектын бер укылышта карый.».

1.3. 40 статьяның 2 пунктына «бирелә» сүзеннән соң «бюджет үтәлешенә һәм бюджет хисаплылыгына анализ булган аңлатма язуы, муниципаль йөкләмәнең үтәлеше һәм (яисә) бюджет ассигнованиеләреннән файдалануның башка нәтиҗәләре турында белешмәләр» сүзләрен өстәргә.

2. Әлеге карарның 1.1 пункты 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында» урнаштыру юлы белән түбәндәге веб-адрес буенча игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://aznakayevo.tatar.ru. урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Азнакай районы Татар Шуган авыл җирлеге Советының бюджет, финанс, салым һәм икътисад мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис Г.З.Мияссарова